ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОТОЛКИШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422966, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с. Малый Толкиш, ул. Центральная, 17

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ ТАЛКЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422966, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Кече Талкыш авылы,
Центральная ур., 17

тел. 884342 3-37-64, e-mail: Mtolk.Ctp@tatar.ru

Постановление — Карар

2022 елның 31 гыйнвары — № 2

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кече Талкыш авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлегендә әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2022 елның 1 февраленнән билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Кече Талкыш авыл җирлеге
башлыгы — Г.Н. Федотов

Чистай муниципаль районының
Кече Талкыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 4933,99 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 699,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1330,94 |
| БАРЛЫГЫ | 6964,68 |

Чистай муниципаль районының
Кече Талкыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Кәфенләү | 2465,5 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 2465,5 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 696,5 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1337,18 |
| БАРЛЫГЫ | 6964,68 |